| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.03.2017** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 565** |

«Чәчәк атучы шәһәр - Зеленодольскига 85 яшь» шәһәр Чәчәкләр фестивален уздыру турында

Шәһәр кешеләрен һәм оешмаларын шәһәр территорияләрен чәчәкле-декоратив бизәүгә җәлеп итү максатында һәм «2016 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре турында Зеленодольск шәһәре Мэрының хисабы турында» 2017 елның 14 февралендәге 118 номерлы карарының 3 пунктын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Чәчәк атучы шәһәр - Зеленодольскига 85 яшь» Чәчәкләр фестивален 2017 елның апреленнән сентябренә кадәр (алга таба - Чәчәкләр фестивале) үткәрергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

2.1. әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча, Чәчәкләр фестивале турында нигезләмәне;

2.2. әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча, шәһәр чәчәкләр фестивален әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составын;

2.3. әлеге карарга 3 нче кушымтада каралганча, чәчәкләр фестивален үткәрү чаралары планын;

3. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге башлыгына буласы чараларны анонслауны һәм барлык массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 17 мартындагы
565 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Чәчәк атучы шәһәр - Зеленодольскига 85 яшь»
Чәчәкләр фестивале турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. «Чәчәк атучы шәһәр - Зеленодольскига 85 яшь» (алга таба - Фестиваль) Чәчәкләр фестивале Зеленодольск шәһәренең 85 еллыгын бәйрәм итү кысаларында уздырыла.

## 2. Фестивальнең максатлары һәм бурычлары

2.1 Фестиваль шәһәр халкында экологик һәм эстетик мәдәният формалаштыру, туристлар өчен кызыклы һәм яшәү өчен уңайлы шәһәр имиджын алга өндәү максатыннан уздырыла.

2.2 Фестивальнең бурычлары:

- шәһәр территориясендә уңайлы экологик мохит һәм эстетик мохит булдыру;
- халыкның туган шәһәрен яратуын тәрбияләү, аларны микрорайоннарны, урамнарны, ишегалларын экологик һәм эстетик үсешкә җәлеп итү;
- шәһәр территорияләрен яшелләндерү буенча оешмаларның һәм халыкның эшчәнлеген стимуллаштыру;
- чәчәклелекне, флористиканы, ландшафт дизайнын һәм чәчәк сервисын үстерү һәм популярлаштыру;
- катнашучыларның иҗади потенциалын гамәлгә ашыру өчен киң мөмкинлек бирү.

## 3.Фестивальдә катнашучылар

3.1 Фестивальдә катнашу өчен түбәндәгеләр чакырыла:

- шәһәрне яшелләндерү белән шөгыльләнүче махсуслаштырылган предприятиеләр;
- экологик оешмалар, клублар һәм һәвәскәр берләшмәләр;
- бакчачылык кооперативлары һәм һәвәскәр чәчәк үстерүчеләр;
- торак милекчеләре ширкәтләре;
- флористика, икебаннар, ландшафт дизайны осталары;
- студияләр, кибетләр һәм чәчәк салоннары;
- орлыклар, утырту материаллары һәм шундый товарлар белән сәүдә итүдә махсуслашкан оешмалар, хосусый эшкуарлар;
- Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы оешмалары;
- махсус әдәбият тәкъдим итүче компанияләр.

## 4. Фестивальне уздыру тәртибе һәм шартлары

4.1 Фестиваль 2017 елның 1 маеннан 31 августына кадәр Зеленодольск шәһәре территориясендә уздырыла.

4.2 Фестиваль үткәрү өчен Фестиваль программасын формалаштыручы Оештыру комитеты төзелә (1 нче кушымта).

4.3 Фестивальдә катнашу өчен 2017 елның 1 апреленнән 10 августына кадәр Оештыру комитетына Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 44 йорт, «Зәңгәр кош» гаилә клубы адресы буенча ,(84371) 7-95-59 телефон номеры яки Ali_bag@list.ru .электрон почта аша заявка тапшырырга кирәк

4.4 Фестиваль кысаларында бакчачылык, флористика, рәсем, «Юбилярга чәчәкләр» темасына иҗади мастер-класслар оештырылачак; «грин-корт» - чәчәкләр, утырту материалы, чәчәк үстерү, яшелләндерү, бакча-парк декоры буенча товарлар ярминкәсе һәм фестивальдә катнашучы фирмалар презентациясе оештырылачак; балалар иҗаты һәм иҗат конкурслары шәһәр территориясен яхшырак төзекләндерү, яшелләндерү һәм чәчәкләр белән бизәү өчен күләмле композицияләр конкурслары, шулай ук Шәһәр көнен бәйрәм итү көнендә үткәреләчәк конкурслар.

## 5. Конкурсларны оештыру һәм уздыру

5.1. Шәһәр чәчәкләр фестивале  конкурслары (алга таба - конкурслар) оешмаларның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм гражданнарның иҗади потенциалын ачыклау һәм бүләкләү максатыннан үткәрелә.

5.2. Конкурсларда катнашу өчен оешмалардан, шәхси эшмәкәрләрдән, шәһәр гражданнарыннан индивидуаль һәм коллектив гаризалар кабул ителә һәм карала.

5.3. Конкурсларда катнашу өчен гаризалар (алга таба - заявка) 2017 елның 1 апреленнән 10 августына кадәр Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 44 йорт, «Зәңгәр кош» гаилә клубы адресы буенча шәһәр чәчәкләр фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба - оештыру комитеты) тарафыннан кабул ителә.

5.4. Катнашучылар язма яисә электрон формада заявка бирә.

5.5. Катнашу өчен заявкалар бланкы, әлеге Фестивальнең нигезләмәсе һәм Чәчәкләр фестивале буенча башка материаллар https://vk.com/zd_flowers төркемендә урнаштырылган

5.6. Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне башкара:

а) конкурслар жюри составын формалаштыра (алга таба - жюри);

б) түбәндәгеләрне оештыра:

- жюри эшен;
- дипломнар әзерләүне;
- конкурсларда җиңүчеләргә дипломнар тапшыруны;

в) конкурслар уздыру турында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту йомгаклары турында материаллар бирә;

г) катнашучыларга урнаштыру схемасын һәм экспозицияләр күләмнәрен бирә;

д) жюри утырышларын уздыру өчен бина бирә;

ж) конкурста катнашучылар тарафыннан бирелә торган материалларның кабул ителүен һәм сакланышын тәэмин итә.

5.7. Конкурслар номинацияләре:

1). «Чиста Зеленодольск - безнең киләчәк шәһәре» конкурсы - балалар плакатларының эко-конкурсы. 1 яшьтән 14 яшькә кадәрге балалар арасында үткәрелә. Конкурска теләсә нинди техникада А1 форматындагы кәгазьдә эшләнгән төсле рәсемнәр кабул ителә. Эшләрне башкарганда ата-аналарының ярдәме дә рөхсәт ителә. Конкурста катнашуга заявкалар 2017 елның 1 апреленнән 30 маена кадәр кабул ителә. Җиңүчеләр «Сабантуй» шәһәр чарасында билгеләнә.

2). «Иң яхшы күләмле арт-композиция» конкурсы.

Конкурста катнашуга заявкалар 2017 елның 1 маеннан 15 июненә кадәр кабул ителә. Бу номинациядә чәчәк-декоратив композицияләр темасы «Зеленодольск - 85» Шуңа күрә шәһәрнең истәлекле урыннарының чәчәк имитациясе булу мәҗбүри. Композицияләрне паркларда һәм скверларда, гомуми кулланышта булган урыннарда, проектларны шәһәрнең баш архитекторы белән алдан килештереп, урнаштырырга киңәш ителә,

3). «Балкондагы яшел оазис»конкурсы.

4). «Юбилей шәһәренең иң яхшы палисаднигы» конкурсы.

Конкурсларда катнашырга 5.7.3 п.һәм 5.7.4 п.- күп фатирлы йортларда яшәүче һәвәскәр чәчәк үстерүчеләр чакырыла. Конкурсларда катнашуга заявкалар 2017 елның 15 маеннан 30 июненә кадәр кабул ителә.

5). «Иң яхшы «Пеларгония» конкурсы - юбилей елы чәчәгенә дәгъва итә торган яран гөле гаиләсеннән бүлмә үсемлеге.

Конкурс һәвәскәр чәчәләр арасында үткәрелә. Конкурска гадәти булмаган зурлыкта, оригиналь формада яки төсләрдә «Пеларгония» бүлмә үсемлекләре кабул ителә. Экспонатларның 20х10 см зурлыгындагы этикеткасы булырга тиеш, ул объекттан уңда куела. Этикекеткада экспонатның исеме, аның ничә еллык булуы, катнашучының исеме күрсәтелә.

6). «Минем бакча чемпионы» конкурсы.

Конкурс һәвәскәр бакчачылар арасында үткәрелә.

Конкурска бакча, дача кишәрлекләрендә үстерелгән җиләк-җимеш кабул ителә. Сайлап алу әлеге төр өчен гадәти булмаган үсемлектән, зурлыгыннан, оригиналь формадан яисә төстән чыгып башкарыла. Экспонатларның 20х10 см зурлыкта этикеткасы булырга тиеш, ул объекттан уңда куела. Этикекеткада экспонатның исеме, зурлыгы, экспонатның авырлыгы, катнашучының исеме күрсәтелә.

7). «Минем кече Ватаным! Зеленодольскка 85 яшь!»балалар рәсемнәре конкурсы

Конкурста 1 яшьтән 14 яшькә кадәрге балалар катнаша. Конкурска теләсә нинди техникада А1 форматындагы кәгазьдә эшләнгән төсле рәсемнәр кабул ителә. Эшләрне башкарганда ата-аналарының ярдәме дә рөхсәт ителә. Конкурста катнашуга заявкалар 2017 елның 1 маеннан 20 августына кадәр кабул ителә.

5.8. Катнашучылар Оештыру комитетында үз номинацияләрен тәкъдим итә ала.

5.9. Фестиваль, аның катнашучылары һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында телевидениедә репортажлар һәм видео рәсемнәр, газета һәм Интернет челтәрендә фотолар рәвешендә яктыртылачак

## 6. Конкурслар йомгаклары

6.1. Конкурс эшләрен бәяләү жюри тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә билгеләнгән конкурслар критерийлары нигезендә үткәрелә.

Жюри, бәяләү нәтиҗәләре буенча, һәр конкурс буенча беренче, икенче һәм өченче урыннарны бирү турында карар кабул итә.

Карар конкурсның һәр катнашучысына карата ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм утырышта катнашучы жюри әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

6.2. Конкурста катнашучылар катнашучы дипломнары, җиңүчеләр - дипломнар һәм истәлекле призлар белән бүләкләнә

6.3. 5.7.1 п. конкурсларында җиңүчеләр «Сабан туе» бәйрәме көнендә, 5.7.2 - 5.7.7п. - Зеленодольск шәһәрен бәйрәм итү көнендә, шәһәрнең бәйрәм мәйданчыкларының берсендә бүләкләнә.

## 7. Финанслау

7.1. Фестивальне оештыруны һәм үткәрүне финанс яктан тәэмин итүне «Чәчәк атучы шәһәр – Зеленодольскига - 85 ел» фестиваленең партнерлары һәм спонсорлары башкара.